ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр раслау хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасына бирелгән, 2018 – 2019 һәм 2021 – 2022 елларда капланырга тиешле бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан үткәрелгән реструктуризация кысаларында бирелгән бюджет кредитлары буенча бурычны реструктуризацияләү датасына түләнмичә калган өлешләр чикләрендә 5 731 143 000 сум күләмендә төзелгән түбәндәге өстәмә килешүләрне расларга:

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы килешүгә 731 143 000 сум кредит бирү хакында 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы өстәмә килешү, әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы килешүгә 4 853 066 000 сум кредит бирү хакында 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы өстәмә килешү, әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә;

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүгә 146 934 000 сум

кредит бирү хакында 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы өстәмә килешү, әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 24 февраль
№ 1-ТРЗ

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредитлары бирү
турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы килешүгә**

**1 номерлы өстәмә килешү**

Мәскәү ш. 2017 елның 25 декабре

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министры урынбасары Л.В. Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «2017 елга һәм 2018, 2019 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2016 елның 19 декабрендәге 415-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы һәм «2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Яклар Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы Килешү (алга таба – Килешү) нигезендә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бирелгән бюджет кредиты буенча Заемщикның йөкләмәләре (бурычы) әлеге Өстәмә килешүне төзү датасына 731 143 000 сум (җиде йөз утыз бер миллион йөз кырык өч мең сум) тәшкил итә дип раслыйлар, шул исәптән:

а) төп бурыч буенча – 731 143 000 сум (җиде йөз утыз бер миллион йөз кырык өч мең сум);

б) бюджет кредиты акчаларыннан фактта файдаланган срок өчен реструктуризация датасына исәпләнгән процентлар буенча - 0 (ноль) сум;

в) бюджет кредиты акчаларын, бюджет кредитыннан файдаланган өчен процентларны вакытында кайтармаган өчен исәпләнгән штрафлар (пенялар) буенча бурыч – 0 (ноль) сум.

2. Әлеге Өстәмә килешү үз көченә кергән көннән Заемщикның әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән йөкләмәләре (бурычы) бер сумма итеп берләштерелә һәм алга таба реструктуризацияләнгән бурычны тәшкил итә.

Реструктуризацияләнгән бурычны кайтару Заемщик тарафыннан 2018 елдан 2024 елга кадәр (шул елны кертеп), 2018 – 2019 елларда ел саен бурыч суммасының 5 проценты күләмендә, 2020 елда бурыч суммасының 10 проценты күләмендә, 2021 – 2024 елларда ел саен 20 процент әлеге Өстәмә килешүнең аерылгысыз өлеше булып торучы кушымтасындагы график (алга таба – График) нигезендә, вакытыннан алда түләү мөмкинлеге белән, тигез өлешләрдә түләнә.

Реструктуризацияләнгән бурычны Заемщик тарафыннан түләү ел саен тиешле елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3. Реструктуризацияләнгән бурычның калган өлешенә 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап реструктуризацияләнгән бурычны түләү йөкләмәләре тулы күләмдә башкарылган көнгә кадәр (шул көнне кертеп) бер елга 0,1 процент күләмендә түләү (алга таба – өлешләп түләгән өчен процентлар) исәпләнә.

2018 – 2024 елларда өлешләп түләгән өчен процентлар түләү реструктуризацияләнгән бурычны каплау белән бергә тиешле елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Реструктуризацияләнгән бурычны вакытыннан алда түләгән очракта өлешләп түләгән өчен процентлар вакытыннан алда түләгән вакытта гамәлгә ашырыла. Монда вакытыннан алда түләгән ел өчен өлешләп түләү процентлары исәпләнми.

Өлешләп түләгән өчен процентлар түләгәндә исәп-хисап документының 104 кырында Заемщик 09211103010015003120 кодын күрсәтә.

4. Әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән бюджет кредиты буенча бурычны реструктуризацияләү Заемщик түбәндәге йөкләмәләрне кабул итү шарты белән үткәрелә:

а) әлеге Өстәмә килешүне имзалаган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча Кредиторга Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы тарафыннан расланган Россия Федерациясе субъекты дәүләт финансын савыктыру буенча, Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәрен арттыруга, Россия Федерациясе субъекты бюджеты чыгымнарын оптимальләштерүгә, шулай ук Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычын кыскартуга юнәлдерелгән чараларны кертеп, чаралар планын тәкъдим итү;

б) 2018 – 2024 елларда Россия Федерациясе субъекты бюджеты кытлыгын тиешле финанс елында кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә

алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 10 процентыннан артмаган күләме дәрәҗәсендә тәэмин итәргә. Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында Россия Федерациясе субъекты законы белән расланган һәм 2017 – 2024 елларда Россия Федерациясе субъекты бюджеты үтәлеше хакында еллык хисап күрсәткечләре буенча гамәлдә булган Россия Федерациясе субъекты бюджеты кытлыгы билгеләнгән күрсәткечтән Россия Федерациясе субъекты милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның башка рәвешләрен сатудан алынган һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты резерв фонды акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларның киму суммасына артырга мөмкин;

в) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2018 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2017 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 45 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2017 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 0 процентыннан артмаган күләмдә;

2019 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2018 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 50 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2018 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 0 процентыннан артмаган күләмдә;

2020 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2019 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 49 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2019 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 0 процентыннан артмаган күләмдә;

2021 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2020 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 48 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2020 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 0 процентыннан артмаган күләмдә;

2022 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2021 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 47 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2021 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 1 процентыннан артмаган күләмдә;

2023 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2022 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 47 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2022 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 2 процентыннан артмаган күләмдә;

2024 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2023 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 43 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2023 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 3 процентыннан артмаган күләмдә;

2025 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2024 елгы кире кайтарылмый торган

керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 40 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2024 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 4 процентыннан артмаган күләмдә;

г) 2018 елның 1 гыйнварына бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме, 2017 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре суммасының 140 процентыннан артык булган, 2019 елның 1 гыйнварына 2018 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре суммасының 120 процентыннан артык булган, 2020 елның 1 гыйнварына бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме, 2019 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре суммасының 100 процентыннан артык булган Россия Федерациясе субъект ларына (үзенә карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 130 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар кулланыла торган, 2018 елның 1 гыйнварына бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме 2017 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре суммасының 70 процентыннан артык булган, 2019 елның 1 гыйнварына бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме 2018 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре суммасының 60 процентыннан артык булган, 2020 елның 1 гыйнварына бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме 2019 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре суммасының 50 процентыннан артык булган Россия Федерациясе субъект лары өчен), шулай ук әлеге пунктның “д” пунктчасы бозылган очракта Россия Федерациясе субъекты бюджеты үтәлешен оештыруны Россия Федерациясе субъекты бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтелгәндә, Россия Федерациясе субъекты бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне Федераль казначылык органы тарафыннан башкару турында Федераль казначылыкның территориаль органы белән Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы арасында төзелгән килешү нигезендә Федераль казначылыкның территориаль органында баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә, Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын алучыларга һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына (администраторларына) шәхси счетлар ачып һәм алып барып тәэмин итәргә, Килешү түбәндәге нигезләмәләрдән тора:

Федераль казначылык органына Россия Федерациясе субъектының бюджет йөкләмәләрен исәпкә алу һәм Россия Федерациясе субъектының

бюджет акчаларын алучыларның акчага кагылышлы йөкләмәләрен түләүне санкцияләү вәкаләтләрен тапшыру турында;

акчаны кичерү чиратлылыгы турында, Россия Федерациясе субъекты бюджетының Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган беренче чираттагы чыгымнары исемлеге;

Россия Федерациясе субъектының беренче чираттагы чыгымнары исемлегенә кертелгән чыгым йөкләмәләре буенча вакыты чыккан кредит бурычы булганда, Россия Федерациясе субъектының беренче чираттагы чыгымнары исемлегенә кертелмәгән чыгым йөкләмәләре буенча касса түләүләре үткәрүгә юл куелмау турында;

д) Россия Федерациясе субъекты бюджетына бары тик Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән, еллык 1 процентка арттырылган төп ставка дәрәҗәсеннән артмаган дәрәҗәдәге ставкалар буенча гына кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан кредитлар җәлеп итү мөмкинлеген тәэмин итү, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан җирле бюджетларга бюджет кредитлары бирү тәртибен билгеләүче югары башкарма органы актында шундый нормаларны билгеләү;

е) әлеге Өстәмә килешүне Россия Федерациясе субъекты законы (законнары) белән раслау һәм әлеге Өстәмә килешү имзаланганнан соң 3 ай эчендә Россия Федерациясе субъекты законы күчермәсен Россия Федерациясе Финанс министрлыгына тәкъдим итү;

ж) ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында закон расланганнан соң 14 эш көне эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгына, реструктуризацияләнгән бурычны каплауга һәм (яисә) өлешләп түләгән өчен процентлар түләүгә юнәлдерелә торган акчалар суммасын күрсәтеп, чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында законнан өземтә бирергә. 2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Россия Федерациясе субъекты бюджеты турындагы законнан күрсәтелгән өземтә әлеге Өстәмә килешү имзаланганнан соң 3 ай эчендә бирелергә тиеш;

з) ел саен хисап елыннан соң килүче елның 25 февраленнән дә соңга калмыйча реструктуризацияләнгән бурыч тулысынча түләнеп беткәнче Кредиторга әлеге пунктның «а»-«д» пунктчаларында каралган реструктуризация шартларының үтәлүе турында мәгълүмат бирү.

5. Заемщик 2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрдә (алга таба – Кагыйдәләр) билгеләнгән шартларны, шулай ук әлеге Өстәмә килешүдә каралган шартларны, реструктуризацияләнгән бурычны каплау һәм (яисә) өлешләп түләү процентларын түләү графигын, шулай ук Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «з» пунктчасы һәм әлеге Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «е» пунктчасы нигезләмәләре үтәлмәгән очракта, Заемщик Кредитор күрсәтелгән

шартларның үтәлмәве турында хәбәр иткән вакыттан алып 60 көн эчендә капланмаган реструктуризацияләнгән бурычны һәм өлешләп түләгән өчен процентларны вакытыннан алда берьюлы каплый, Заемщик тиешле чорда фактта түләгән өлешләп түләү процентлары суммаларын чигереп, процентлар түли.

Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б» - «г» пунктчалары һәм әлеге Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «б»-«в» пунктчалары нигезләмәләре үтәлмәгәндә Заемщик Кредитор күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәр иткән вакыттан алып 60 көн эчендә капланмаган реструктуризацияләнгән бурычны һәм өлешләп түләгән өчен процентларны вакытыннан алда каплый, шулай ук Россия Федерациясе субъекты бюджет кытлыгының иң чик күрсәткечләреннән арткан күләмдәге һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләмендәге бурычын, шул исәптән Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъектының кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлары буенча йөкләмәләрен вакытыннан алда каплый, ләкин агымдагы елның 1 июленә кадәр реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменең 20 процентыннан да артыгын түгел.

Заемщикның Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «а», «д» - «ж», «и» һәм «к» пунктчаларын, шулай ук Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «а», «г» - «д», «ж» һәм «з» пунктчаларын үтәмәве Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылык чараларын куллануга китерә.

Заемщик Кредиторның Өстәмә Килешүнең әлеге пунктындагы беренче һәм икенче абзацларында күрсәтелгән таләпләрен үтәмәгәндә әлеге Өстәмә Килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән сумма Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә федераль бюджетка түләнергә тиеш.

6. Яклар Заемщикның Килешүнең 3.2 пунктындагы «г», «з» пунктчаларында (2017 елда Россия Федерациясе субъекты бюджеты кытлыгын тәэмин итү өлешендә), «к», «л» һәм «н» (2017 елда Россия Федерациясе субъекты бюджеты кытлыгын тәэмин итү турында мәгълүмат бирү өлешендә) күрсәтелгән йөкләмәләре аның тарафыннан әлеге Өстәмә Килешү төзелгәннән соң үтәлергә тиеш дип килештеләр.

7. Яклар Заемщикның Килешүнең 3.2 пунктындагы «а» - «в», «д» - «ж» пунктчаларында (Өстәмә Килешүнең 6 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш), «и», «м», «н» (Өстәмә Килешүнең 6 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш), һәм «о» пунктында күрсәтелгән 3.2 йөкләмәләре аның тарафыннан әлеге Өстәмә Килешү имзаланган көннән үтәлмәскә тиеш дип килештеләр.

8. Килешүнең әлеге Өстәмә Килешү белән кагылмаган һәм аңа каршы килми торган башка шартлары үзгәрешсез кала һәм Яклар алар буенча үз йөкләмәләрен раслыйлар.

9. Әлеге Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә.

10. Әлеге Өстәмә килешү, Кушымтаны да кертеп, һәр як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 9 биттә төзелде.

## 11. Юридик адреслар

**Кредитор:** Россия Федерациясе Финанс министрлыгы,
Ильинка ур., 9, Мәскәү ш., 109097.

**Заемщик:** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты,
Ирек мәйданы, 1, Казан ш., 420060.

## Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| **Кредитордан:** | **Заемщиктан:** |
| Россия Федерациясе<br>Финанс министры урынбасары | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры |
| __________________Л.В. Горнин | _________________А.В. Песошин |
| **М.У.** | **М.У.** |

Федераль бюджеттан Татарстан
Республикасы бюджеты кытлыгын
өлешчә каплау өчен Татарстан
Республикасы бюджетына бюджет
кредиты бирү турында 2017 елның
25 декабрендәге 01-01-06/06-72 номерлы
килешүгә 2016 елның 14 апрелендәге
1 номерлы өстәмә килешүгә
кушымта

Реструктуризацияләнгән бурычны һәм (яисә) өлешләп түләгән өчен
процентларны кайтару **графигы**

| Кайтару срогы | | Реструктуризацияләнгән бурыч (сумнарда) | Реструктуризацияләнгән бурычны кайтару суммасы (сумнарда) | Өлешләп түләгән өчен процентлар (сумнарда) | Түләү өчен барлыгы (сумнарда) |
|---|---|---|---|---|---|
| 2018 | 30.11.2018 | 731 143 000,00 | 36 557 150,00 | 728 038,14 | 37 285 188,14 |
| 2019 | 29.11.2019 | 694 585 850,00 | 36 557 150,00 | 691 380,84 | 37 248 530,84 |
| 2020 | 30.11.2020 | 658 028 700,00 | 73 114 300,00 | 651 835,96 | 73 766 135,96 |
| 2021 | 30.11.2021 | 584 914 400,00 | 146 228 600,00 | 572 494,99 | 146 801 094,99 |
| 2022 | 30.11.2022 | 438 685 800,00 | 146 228 600,00 | 426 266,38 | 146 654 866,38 |
| 2023 | 30.11.2023 | 292 457 200,00 | 146 228 600,00 | 280 037,79 | 146 508 637,79 |
| 2024 | 29.11.2024 | 146 228 600,00 | 146 228 600,00 | 133 443,59 | 146 362 043,59 |
| | | | | | |
| Барлыгы | х | | 731 143 000,00 | 3 483 497,69 | 734 626 497,69 |

**Якларның имзалары**

**Кредитордан:**

Россия Федерациясе
Финанс министры урынбасары

__________________Л.В. Горнин

**Заемщиктан:**

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

__________________А.В. Песошин

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредитлары бирү
турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы килешүгә**

**1 номерлы өстәмә килешү**

Мәскәү ш. 2017 елның 25 декабре

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министры урынбасары Л.В. Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «2017 елга һәм 2018, 2019 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2016 елның 19 декабрендәге 415-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы һәм «2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Яклар Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы Килешү (алга таба – Килешү) нигезендә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бирелгән бюджет кредиты буенча Заемщикның йөкләмәләре (бурычы) әлеге Өстәмә килешүне төзү датасына 4 853 066 000 сум (дүрт миллиард сигез йөз илле өч миллион алтмыш алты мең сум) тәшкил итә дип раслыйлар, шул исәптән:

а) төп бурыч буенча – 4 853 066 000 сум (җиде йөз утыз бер миллион йөз кырык өч мең сум);

б) бюджет кредиты акчаларыннан фактта файдаланган срок өчен реструктуризация датасына исәпләнгән процентлар буенча - 0 (ноль) сум;

в) бюджет кредиты акчаларын, бюджет кредитыннан файдаланган өчен процентларны вакытында кайтармаган өчен исәпләнгән штрафлар (пенялар) буенча бурыч – 0 (ноль) сум.

2. Әлеге Өстәмә килешү үз көченә кергән көннән Заемщикның әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән йөкләмәләре (бурычы) бер сумма итеп берләштерелә һәм алга таба реструктуризацияләнгән бурычны тәшкил итә.

Реструктуризацияләнгән бурычны кайтару Заемщик тарафыннан 2018 елдан 2024 елга кадәр (шул елны кертеп), 2018 – 2019 елларда ел саен бурыч суммасының 5 проценты күләмендә, 2020 елда бурыч суммасының 10 проценты күләмендә, 2021 – 2024 елларда ел саен 20 процент әлеге Өстәмә килешүнең аерылгысыз өлеше булып торучы кушымтасындагы график (алга таба – График) нигезендә, вакытыннан алда түләү мөмкинлеге белән, тигез өлешләрдә түләнә.

Реструктуризацияләнгән бурычны Заемщик тарафыннан түләү ел саен тиешле елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3. Реструктуризацияләнгән бурычның калган өлешенә 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап реструктуризацияләнгән бурычны түләү йөкләмәләре тулы күләмдә башкарылган көнгә кадәр (шул көнне кертеп) бер елга 0,1 процент күләмендә түләү (алга таба – өлешләп түләгән өчен процентлар) исәпләнә.

2018 – 2024 елларда өлешләп түләгән өчен процентлар түләү реструктуризацияләнгән бурычны каплау белән бергә тиешле елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Реструктуризацияләнгән бурычны вакытыннан алда түләгән очракта өлешләп түләгән өчен процентлар вакытыннан алда түләгән вакытта гамәлгә ашырыла. Монда вакытыннан алда түләгән ел өчен өлешләп түләү процентлары исәпләнми.

Өлешләп түләгән өчен процентлар түләгәндә исәп-хисап документының 104 кырында Заемщик 09211103010015003120 кодын күрсәтә.

4. Әлеге Өстәмә килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән бюджет кредиты буенча бурычны реструктуризацияләү Заемщик түбәндәге йөкләмәләрне кабул итү шарты белән үткәрелә:

а) әлеге Өстәмә килешүне имзалаган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча Кредиторга Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы тарафыннан расланган Россия Федерациясе субъекты дәүләт финансын савыктыру буенча, Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәрен арттыруга, Россия Федерациясе субъекты бюджеты чыгымнарын оптимальләштерүгә, шулай ук Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычын кыскартуга юнәлдерелгән чараларны кертеп, чаралар планын тәкъдим итү;

б) 2018 – 2024 елларда Россия Федерациясе субъекты бюджеты кытлыгын тиешле финанс елында кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 10 процентыннан артмаган күләме дәрәҗәсендә тәэмин итәргә. Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында Россия Федерациясе субъекты законы белән расланган һәм 2017 – 2024 елларда Россия Федерациясе субъекты бюджеты үтәлеше хакында еллык хисап күрсәткечләре буенча гамәлдә булган Россия Федерациясе субъекты бюджеты кытлыгы билгеләнгән күрсәткечтән Россия Федерациясе субъекты милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның башка рәвешләрен сатудан алынган һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты резерв фонды акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларның кимү суммасына артырга мөмкин;

в) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2018 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2017 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 45 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2017 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 0 процентыннан артмаган күләмдә;

2019 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2018 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 50 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2018 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 0 процентыннан артмаган күләмдә;

2020 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2019 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 49 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2019 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч

йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 0 процентыннан артмаган күләмдә;

2021 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2020 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 48 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2020 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 0 процентыннан артмаган күләмдә;

2022 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2021 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 47 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2021 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 1 процентыннан артмаган күләмдә;

2023 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2022 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 47 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2022 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 2 процентыннан артмаган күләмдә;

2024 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2023 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 43 процентыннан артмаган күләмдә, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты дәүләт бурычының гомуми күләме өлешен 2023 елгы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъекты кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлар буенча Россия Федерациясе субъекты бурыч

йөкләмәләренең гомуми күләме өлеше Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре суммасының 3 процентыннан артмаган күләмдә;

